ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «НОВОИШТЕРЯКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЯҢА ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2022 елның 20 сентябре

№ 14

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә, «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында»;

б) карарның 1 пунктында «Муниципаль берәмлек башкарма комитеты» сүзләрен «муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга;

в) «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карары 1 нче кушымтасының исемендә «муниципаль берәмлекнең башкарма комитетында (туганнары булган) сүзләрен «муниципаль берәмлектә» сүзләренә алмаштырырга;

г) Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карары 2 нче кушымтасының «муниципаль берәмлекнең башкарма комитетында (туганнары булмаган) сүзләрен «муниципаль берәмлектә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Лениногорск районы, Яңа Иштирәк авылы, Үзәк урам, 7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Р.Мәүлетова